**Олы Әтнә урта мәктәбендә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы уңаеннан 25-30 нчы гыйнвар аралыгында уздырылган чаралар**



27 нче гыйнвар көнне 7-11 нче сыйныф укучылары Әтнә дәүләт драма театрына Гөлүсә Батталованың “Җомга базары” спектаклен карарга бардык. Җырлы-биюле бу спектакльдән алган тәэсирләр укучылар күңелендә озак сакланыр.




“Рәссамнар да бизи телебезне” исеме астында уздырылган чарада СНГ профессиональ рәссамнар берлеге әгъзасы, районыбызның күренекле рәссамы Вәлиуллин Илдар Хәйдәр улы күргәзмәсе белән таныштык. Бу картиналар да туган телебезгә, туган җиребезгә, гореф-гадәтләребезгә мәхәббәт белән иҗат ителгән.